ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 22 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш); 2025, № 56 (I өлеш); 2026, № 17 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен агач әзерләү тәртибе**

1. Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен агач әзерләү гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен торглар үткәрмичә урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе (алга таба – үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе) нигезендә башкарыла.

2. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзергә теләгән граждан милкендәге, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, индивидуаль торак төзелеше яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлегендә торак йорт һәм ишегалды корылмалары төзү, торак йортны һәм ишегалды корылмаларын төзекләндерү максатларында үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзегәндә әлеге Законның

3 статьясындагы 4 өлешенең 3 пункты нигезендә билгеләнгән түләү ставкасына, граждан түбәндәге гражданнар категорияләренең берсенә караган очракта, 0,5 киметү коэффициенты кулланыла:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары;

2) өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар, өлкән балага 18 яшь яисә 23 яшь тулганчы, ул белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку рәвешендә белем алган очракта, яисә балачактан инвалид булган өлкән балага 23 яшь тулганчы;

3) затлар:

а) махсус хәрби операция барышында, Россия Федерациясе территориясенә коралды басып керүгә каршы тору буенча, Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Россия Федерациясе субъектларының махсус хәрби операция үткәрү районнары янәшәсендәге территорияләрендә хәрби провокация барышында бурычларны үтәүче (үтәгән) (катнашучы (катнашкан), бурычларны үтәүгә ярдәм итүче (ярдәм иткән), бурычларны үтәүне тәэмин итү өчен җибәрелгән);

б) махсус хәрби операция барышында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм итүче оешмалар белән контракт төзегән (башка хокукый мөнәсәбәтләрдә булган);

4) әлеге өлешнең 3 пунктында күрсәтелгән һәлак булган (вафат булган) затның хатыны (ире);

5) янгын яисә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл аркасында торак урыннарын югалткан гражданнар.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән гражданнарның берничә категориясенә бер үк вакытта кергән гражданга 0,5 киметү коэффициенты белән түләү ставкасын куллану хокукы граждан сайлаган бер категория буенча бирелә.

4. Торак йортның һәм (яисә) җир кишәрлегенең 0,5 киметү коэффициенты белән түләү ставкасын куллану хокукына ия берничә милекчесе булганда, күрсәтелгән хокук мондый милекчеләрнең һәркайсына бирелә.

5. Гражданның милкендә берничә күчемсез милек объекты булган очракта, 0,5 киметү коэффициенты белән түләү ставкасын куллану хокукы граждан сайлаган бер объектка бирелә.

6. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзергә теләгән граждан (алга таба – гариза бирүче) вәкаләтле органга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү турында гариза (алга таба – гариза) белән мөрәҗәгать итә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны (тору урыны) турында белешмәләр, шәхесен таныклый торган документ белешмәләре;

2) гариза бирүчене әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән гражданнар категориясенә кертү турында белешмәләр (булган очракта);

3) чикләрендә урман утыртмаларын сату-алу күздә тотыла торган урманчылык исеме;

4) агачның таләп ителә торган күләме, аның сыйфат күрсәткечләре һәм аны әзерләү максаты;

5) гаризаны карау нәтиҗәләре турында гариза бирүчегә хәбәр итү ысулы.

7. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән гражданнар категориясенә кергән гариза бирүче гаризага түбәндәгеләрне кушып бирә:

1) гариза бирүчене әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән гражданнар категориясенә кертүне раслый торган документны;

2) гариза бирүче милкендәге, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, индивидуаль торак төзелеше яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлегенә хокукны билгели торган документны;

3) гариза бирүче милкендәге, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, индивидуаль торак төзелеше яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлегендә урнашкан торак йортка хокукны билгели торган документны (торак йортны һәм ишегалды корылмаларын төзекләндерү өчен агач әзерләгән очракта).

8. Әлеге статьяның 7 өлешендә каралган документлар әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән гражданнар категориясенә кергән гариза бирүче тарафыннан тапшырылмаган очракта, вәкаләтле орган аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

9. Гариза дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша язма рәвештә яисә «Дәүләт хезмәтләре (функцияләре) һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелергә мөмкин.

10. Гаризалар вәкаләтле орган тарафыннан аларның керү чиратлылыгы тәртибендә карала.

11. Гариза кергән көннән алып 10 көн эчендә вәкаләтле орган гариза бирүче белән үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзи яисә мондый шартнамә төзүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм гариза бирүчегә аны гаризада күрсәтелгән ысул белән җибәрә. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карарда мондый баш тартуның сәбәбе күрсәтелергә тиеш.

12. Вәкаләтле орган үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карарны түбәндәге очракларда кабул итә:

1) тапшырылган документларда тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат булса;

2) агачның гаризада күрсәтелгән күләме әлеге Законның 7 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән нормативлардан артып китсә;

3) гариза бирүче күрсәткән урманчылыкта гаризада күрсәтелгән таләп ителә торган сыйфат күрсәткечләренә ия агач күләмнәрен әзерләү өчен җитәрлек урман утыртмалары булмаса;

4) әлеге Законның 7 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән сроклар үтәлмәсә.

13. Чикләрендә гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен агач әзерләүгә яраклы урман утыртмалары урнашкан урманчылыклар турында мәгълүмат

вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.»;

2) 7 статьяның 1 өлешендә:
а) икенче абзацта «йорт» сүзен «торак йорт» сүзләренә алмаштырырга;
б) өченче абзацта «йортны» сүзен «торак йортны» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 90 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе
Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2026 ел, 25 июль
№ 50-ТРЗ